ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК РАЙОНЫ
НОРЛАТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**«03» ноябрь 2022 ел**

**КАРАР**
**№32**

Татарстан Республикасы Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»№131-ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (10.09.2020 ред.), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә, аны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Халык җыены карары белән муниципаль берәмлек (торак пункт (яисә аның территориясе өлешендәге) түләүләр күләме киметелергә мөмкин булган гражданнарның аерым категорияләре билгеләнә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм түбәндәге адреслар буенча Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М.Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы» үзәк клуб системасы) мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Норлат авыл җирлеге башлыгы И. М. Саттаров